№52 (1092)
30 август
2006 ел

Көмеш кыңгырау

1996 елның 1 гыйнварыннан чыга башлады

Серле утрау сезне көтә

Дусларым! Серле утрауда яшисегез килсә, аны пластилиннан әвәләгез. Андагы үсемлекләрне, агачларны, хайваннарны, кошларны алдан ук күз алдына китерегез. Анда кешеләр яшәрме? Аларкыргый әллә диңгез һәлакәтенә очрап, утрауга тукталган моряклармы?

Торттан бушаган түгәрәк тартма яки иске кәстрүл әзерләгез. Бу- утрау булачак. Тирә-ягына яшел, зәңгәр тукыма кисәкләре яки кәгазьләр салып чыгыгыз. Димәк, утравыгыз әллә кайдан дулкыннар өстеннән күренеп торачак. Ә утрауда нәрсәләр булачагын шушы китапчыктан белеп була. Әти-әниләрегезне, дусларыгызны чакырыгыз - бергә-бергә күңеллерәк булыр. Утрауга "җан" кергәч, берәр әкият, хикәя дә яза аласыз.

Мондый утрауны ясар өчен сезгә иң элек -пластилин, сәйләннәр, сәдәфләр, тимерчыбык, шешә, фломастер,ручка капкачлары, коктейль эчә торган торбачыклар, агач "энәләр" (теш чистарткычлар), шырпы, төсле кәгазь, чүпрәк, салфеткалар кирәк булыр.

"Көмеш кыңгырау" остаханәсе

Куе куаклар, зифа хөрмәләр



Безнең утравыбызга төрле үсемлекләр дә кирәк. Моның өчен төрле төстәге түгәрәкләр һәм җәймәләр әвәлибез. Пычак белән (пластилин кисә торган) кискәлибез, шырпы белән тишекләр һәм чокырчыклар ясыйбыз. Бу ташлар һәм чирәм булачак. Аларга куаклыклар һәм агачлар утыртыла. Куаклыкларны пластилин ботаклардан ясыйбыз, яфраклар да “әләбез”. Агачлар егылмасын өчен аларның кәүсәләрен каләмгә, таякчык, тимерчыбыкларга утыртабыз. Аерым-аерым өлешләрдән җыйсаң, хөрмә агачы килеп чыга. Кәүсәләрен очлы шырпы белән тырмап чыксак, чын агач кайрыларына охшаячак. Агач ботакларына пластилин җиләк-җимешләр элеп була.





Канатлы дуслар





Иң элек утрауга кемнәр килә? Дөрес, кошлар! Канатларын кагып, җырларын сузып, алар кешеләрне көтәләр. Тутый кошны әвәләр өчен озынча түгәрәк кирәк булыр. Шунда ук бераз очлайтып баш та ясыйбыз. Койрык, канатлар һәм шаян бүреген аерым әвәлибез. Канатларны тутый кош очып китәрдәй яки ял иткән шикелле итеп куябыз. Алсу фламингоның муены, томшыгы һәм аяклары төсле озынча “бүрәнәчек”ләрдән тора. Озын, нечкә муенны матур итеп бөклә һәм гәүдәсенә куй (“егылып” төшмәсен өчен). Ә аяклары - пластмасса таякчыклар. Ә ерткыч кош-грифның канатлары көчле, томшыгы - кармак кебек, өске томшыгы-ак. Ул пластилин кыяда утыра. Ә менә бу тавис кошы гүя әкият битләреннән төшкән. Искиткеч матур койрыгын ярымтүгәрәкләп җәеп җибәргән дә, ямь-яшел чирәмдә йөренеп тора, үз-үзенә сокланып бетә алмый.



Еланнар - сөйралучелар

Еланнарны әвәләве иң җиңеле. Озынча "бүрәнә"чекләр әзерлибез. Койрык башын нечкәрәк итәбез. Күзләренә сәйләннәр куябыз, гәүдәләренә төрле таплар, сызыклар ясыйбыз. Еланнарны үрмәләтеп тә, агачка сырылган кебек тә, сикерергә әзерләнгән шикелле итеп тә куярга була.



Ташбаканы әвәләве дә авыр түгел. Шар ясыйбыз, аны прәннек шикелле итеп изәбез, кечкенәрәк баш һәм аяклар беркетәбез. Кабырчыгына пычак очы белән рәсем ясыйбыз яки сәдәпләр тезеп чыгабыз.





Крокодилның эше күбрәк булыр. Кишер-гәүдә әвәлибез, ачык авызлы баш ясыйбыз һәм аны гәүдә белән тоташтырабыз, тәпиләрен сырлыйбыз. Крокодил тиресен тырмап яки нечкә баучыклар ясап бизибез.



Тояклылар

Кыргый кәҗәләрсез, зебраларсыз, озын муенлы җирафларсыз утрау буламы инде? Әйдәгез,





аларны да әвәләп карыйк. Бу хайваннарның барысының да гәүдәләре озынча, аяклары озын, нечкә. Ә жирафның муены тагын да озынрак. Пластилин - фигуралар ныклап басып торсыннар өчен, аякларын гәүдәнең ике ягына да тигез урнаштырырга һәм тоякларын бераз җәергә кирәк.





Көчлеләр һәм зурлар

Көчлеләр һәм зурлар

Утрау буйлап җир селкетеп кемнәр килә дисезме? Филләр, су сыерлары,



мөгезборыннар су эчәргә төшәләр. Аларны әвәләр өчен пластилин да бик күп кирәк булачак. Ә инде соры, коңгырт төстәге пластилин



булмаса, су сыерын күгелҗем итәргә дә була бит. Бу утрауда чөнки искиткеч хайваннар яши. Алсу фил, сары мөгезборын...

Утрау халкы

Ниһаять, чират утрау кешеләренә дә җитте. Алар зифа буйлы, тәннәре шоколад төсендә. Киемнәренә килсәң, пальма яфракларыннан тегелгән итәкләр генә.













Картинкәләр әвәлибез



Катыргы, такта яки керамик плитә әзерләгез. Шуны пластилин белән юка гына итеп каплагыз. Бу картинаның нигезе-фоны булачак. Ул төнге яисә иртәнге күк, йомшак





яки явыз диңгез, ком яки ташлар төсендә булырга мөмкин. Аерым детальләрне әвәләп рәсемгә ябыштырабыз. Пластилин рәсемнәрне очлы таяк, каләм, шырпы белән ясау уңайлы.

Көмеш кыңгырау

Баш мөхәррир
Нәсимә САДЫЙКОВА

"Көмеш кыңгырау"ны гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" массакүләм коммуникацияләр буенча Татарстан Республикасы агентлыгы.

"Көмеш кыңгырау" газетасы Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 466нчы номерлы таныклык белән теркәлде.

Адрес: 423802, Чаллы шәһәре, ГЭС бистәсе, Гидротөзүчеләр урамы, 10нчы йорт, 429нчы бүлмә. "Көмеш кыңгырау" газетасы редакциясе.
E-mail:komesh_k@List.ru

Җаваплылыгы чикләнгән "Глагол" ширкәте типографиясендә басылды. Язмаларның эчтәлеге һәм аларны газетада урнаштыруның сыйфаты өчен типография җавап бирми.

Басарга кул куелды
29.08.2006

Индекс - 31700
Тираж - 2850